Республика Татарстан Совет Большенуркеевского сельского поселения Сармановского муниципального района Республики Татарстан		Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы

РЕШЕНИЕ **КАРАР**

2022 елның 21 апреле № 40

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 06 августындагы 49 номерлы Совет карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлегендә территориаль иҗтимагый үзидарә турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 06 августындагы 49 номерлы Совет карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1) 14 статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) инициатив проект турында фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Интернет челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Зур Нөркәй авыл җирлеге
Советы рәисе Р.М.Гайсин